| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.08.2018 г.Казань № 825

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 4 октяберендә 4908 номеры белән теркәлде

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 26 ноябрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 908 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәләре (бүлекләре) җитәкчеләренә, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурслар үзәге» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесенә, Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлеге территориясендә гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү вәкаләтләре бирелгән оешмаларга Регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә.

3. «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 июнендәге

435 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгын, «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 04 февралендәге 61 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгының 1 пунктын, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 26 июнендәге 435 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 09 сентябрендәге 679 номерлы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары Ю.И.Абдреевны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова